**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2025 елның 22 декабрендәге 4599 номерлы карары**

**Казан шәһәре Идел буе районының Р.Гәрәев урамында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1-2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 469 кв.м;
- үзләренә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары 16:50:000000:23772, 16:50:171202:2969, 16:50:171202:2958, 16:50:171202:276, 16:50:171202:2970;
- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталлары – 16:50:171202, 16:50:171124;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы, Р.Гәрәев урамы;
- билгеләү максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү;
- билгеләү вакыты: 2028 елның 31 декабренә кадәр;

1.2. гариза бирүче: «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалану өчен материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 22 декабрендәге
4599 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре




| Масштаб: 1:1000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:171202, 16:50:171124 | кадастр кварталы |
| 16:50:000000:23772, 16:50:171202:2969, 16:50:171202:2958, 16:50:171202:276, 16:50:171202:2970 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

___________________________________